ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.09.2023 г. Казань № 126-5/т-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 3 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2023 елның 1 сентябрендәге утырышының 34-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.10.2020 № 106-3/т-2020, 03.02.2021 № 1-1/т-2021, 09.12.2021 № 478-17/т-2021, 25.05.2022 № 69-8/т-2022, 24.08.2022 № 143-21/т-2022 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Тарифларны билгеләү турында гариза мөрәҗәгать итү көнендә (эш көне дәвамында) теркәлә. Гариза ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көнендә теркәлә.»;

23 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләре белән алмаштырырга;

2 нче кушымтада:

13 нче таблицада «субъектның башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14 нче таблицада «субъектның башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

17 нче таблицада «субъектның башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

18 нче таблицада «субъектның башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина